**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯШЕЛ ҮЗӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БИШНӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

КАРАР

№ 253

2019 елның 13 декабре

Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге Советының карарларын үз көчен югалткан дип тану турында

Муниципаль хокукый актлар системасын актуальләштерү максатыннан, Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге Советынын түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип санарга:

- 2005 елның 18 ноябрендәге 10 номерлы «җир салымы турында» карары;
- 2006 елның 17 ноябрендәге 40 номерлы «җир салымы турында» карары;
- 2007 елның 30 октябрендәге 74 номерлы «Җир салымын түләү ставкаларын, тәртибен һәм срокларын гамәлгә кертү турында» карары;
- 2008 елның 10 ноябрендәге 112 номерлы «Җир салымын түләү ставкаларын, тәртибен һәм срокларын гамәлгә кертү турында» карары;
- 2009 елның 15 октябрендәге 150 номерлы «Җир салымын түләү ставкаларын, тәртибен һәм срокларын гамәлгә кертү турында» карары;
- 2010 елның 21 октябрендәге 4 номерлы «2011 елда Бишнә авыл җирлеге территориясендә җир салымын түләү ставкалары, тәртибе һәм сроклары турында» карары.

2 Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет" мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук: Бишнә авыл җирлеге мәгълүмат стендларында түбәндәге адресларда урнаштырырга: Бишнә авылы, Үзәк урам, 5 йорт (җирлек администрациясе бинасы), Мәктәп урамы, 10 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

**Бишнә авыл**
**җирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе:** **И.М.Фатхуллин**